| | | |
|---|---|---|
| МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

05.12.2019 г.Казань № 1084

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2019 елның 25 декабрендә 6421 номеры белән теркәлде

Торак урыннан һәм (яки) торак йорттан файдаланганда коммуналь хезмәтләрне кулланучы гражданнар тарафыннан коммуналь хезмәтләр өчен кертелә торган түләү күләмен фактик арттыру Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә коммуналь хезмәтләр өчен гражданнар тарафыннан кертелә торган түләү күләмен үзгәртүнең билгеләнгән чик дәрәҗә (максималь) индексларын арттырып җибәргән очракта компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау хакында

«Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә боерык бирәм:

1. Торак урыннан һәм (яки) торак йорттан файдаланганда коммуналь хезмәтләрне кулланучы гражданнар тарафыннан коммуналь хезмәтләр өчен кертелә торган түләү күләмен фактик арттыру Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә коммуналь хезмәтләр өчен гражданнар тарафыннан кертелә торган түләү күләмен үзгәртүнең билгеләнгән чик дәрәҗә (максималь) индексларын арттырып җибәргән очракта компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең кушымтада бирелгән административ регламентын (алга таба – Регламент) расларга.

2. «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе директоры Р.Р.Фәйзуллинга Регламент нигезләмәләренең тайпылышсыз үтәлүен тәэмин итәргә.

3. Әлеге боерык үтәлешен тикшерүдә тотуны министр урынбасары Н.В.Бутаевана йөкләргә.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 13.12.2019 №1084 боерыгы белән расланды

Торак урыннан һәм (яки) торак йорттан файдаланганда коммуналь хезмәтләрне кулланучы гражданнар тарафыннан коммуналь хезмәтләр өчен кертелә торган түләү күләмен фактик арттыру Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә коммуналь хезмәтләр өчен гражданнар тарафыннан кертелә торган түләү күләмен үзгәртүнең билгеләнгән чик дәрәҗә (максималь) индексларын арттырып җибәргән очракта компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

## 1. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

1.1. Торак урыннан һәм (яки) торак йорттан файдаланганда коммуналь хезмәтләрне кулланучы гражданнар тарафыннан коммуналь хезмәтләр өчен кертелә торган түләү күләмен фактик арттыру Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә коммуналь хезмәтләр өчен гражданнар тарафыннан кертелә торган түләү күләмен үзгәртүнең билгеләнгән чик дәрәҗә (максималь) индексларын арттырып җибәргән очракта компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең әлеге административ регламенты (алга таба – Регламент) торак урыннан һәм (яки) торак йорттан файдаланганда коммуналь хезмәтләрне кулланучы гражданнар тарафыннан коммуналь хезмәтләр өчен кертелә торган түләү күләмен фактик арттыру Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә коммуналь хезмәтләр өчен гражданнар тарафыннан кертелә торган түләү күләмен үзгәртүнең билгеләнгән чик дәрәҗә (максималь) индексларын арттырып җибәргән очракта компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү (алга таба – дәүләт хезмәте) стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Гариза бирүчеләр булып торак урыннан һәм (яки) торак йорттан файдаланганда коммуналь хезмәтләрне кулланучы гражданнар тарафыннан коммуналь хезмәтләр өчен кертелә торган түләү күләменең фактик артуы Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә коммуналь хезмәтләр өчен гражданнар тарафыннан кертелә торган түләү күләмен үзгәртүнең билгеләнгән чик дәрәҗә (максималь) индексларын арттырып җибәргән гражданнар.

1.3. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы муниципаль районында яисә шәһәр округында гариза бирүченең даими яшәү урыны буенча «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе бүлеге (алга таба – Үзәк бүлеге) тарафыннан күрсәтелә.

1.3.1. Үзәк бүлегенең урнашкан урыны, эш графигы, белешмә телефоннары, электрон почта адресы турындагы мәгълүмат Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының (алга таба –

Министрлык) рәсми сайтында, «Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре реестры» дәүләт мәгълүмат системасында һәм Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләре порталында урнаштырылган. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр әлеге Регламентның белешмәлек кушымтасында китерелгән.

Үзәк бүлегенең эш графигы: көн саен, шимбә һәм якшәмбедән кала, «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесенең (алга таба – Үзәк) эчке тәртип кагыйдәләрендә билгеләнә торган эш сәгатьләрендә.

Гаризалар кабул итү графигы: көн саен, шимбә һәм якшәмбедән кала, Үзәкнең эчке тәртип кагыйдәләрендә билгеләнә торган эш сәгатьләрендә.

1.3.2. Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат түбәндәгечә алынырга мөмкин:

1) Үзәк бүлекләрендә урнашкан, дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текстлы мәгълүматларны үз эченә алган, хезмәт күрсәтүләр турындагы мәгълүмат стендлары аша. Татарстан Республикасының дәүләт телләрендәге мәгълүмат стендларында урнаштырыла торган дәүләт хезмәте турындагы мәгълүмат әлеге Регламентның 1.4.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1пунктларындагы (пунктчаларындагы) белешмәләрне үз эченә ала;

2) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре ярдәмендә – (алга таба – «Интернет» челтәре):

Министрлыкның http://mtsz.tatarstan.ru рәсми сайтында;

Татарстан Республикасының Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatar.ru/);

Дәүләт хезмәтләренең һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru/);

3) Үзәк бүлегенә, Үзәккә, Министрлыкка телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефон аша);

4) Үзәк бүлегенә, Үзәккә, Министрлыкка язмача мөрәҗәгать иткәндә (шул исәптән электрон документ рәвешендә)(mtsz@tatar.ru). mtsz@tatar.ru).

1.4. Дәүләт хезмәте түбәндәгеләргә нигезләнеп күрсәтелә:

«Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2011, № 15, 2036 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2006, № 31, 3451 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон), (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, № 31, 4179 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы указы (алга таба – Россия Федерациясе Президентының 601 номерлы указы) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 07.05.2012, № 19, 2338 статья);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен гражданнарның түләү түләмен үзгәртү индексларын формалаштыру турында» 2014 елның 30 апрелендәге 400 номерлы карары,

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәсьәләләре» 2007 елның 15 августындагы 388 номерлы карары («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм күрсәтмәләре һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2007, № 33, 1178 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 02 ноябрендәге 880 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе (алга таба – 880 номерлы тәртип) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы» журналы, 2010, №46, 2144 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Торак урыннан һәм (яки) торак йорттан файдаланганда коммуналь хезмәтләрне кулланучы гражданнар тарафыннан коммуналь хезмәтләр өчен кертелә торган түләү күләмен фактик арттыру Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә коммуналь хезмәтләр өчен гражданнар тарафыннан кертелә торган түләү күләмен үзгәртүнең билгеләнгән чик дәрәҗә (максималь) индексларын арттырып җибәргән очракта компенсация билгеләү тәртибен раслау турында» 2019 елның 17 октябрендәге 918 номерлы карары белән расланган Торак урыннан һәм (яки) торак йорттан файдаланганда коммуналь хезмәтләрне кулланучы гражданнар тарафыннан коммуналь хезмәтләр өчен кертелә торган түләү күләмен фактик арттыру Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә коммуналь хезмәтләр өчен гражданнар тарафыннан кертелә торган түләү күләмен үзгәртүнең билгеләнгән чик дәрәҗә (максималь) индексларын арттырып җибәргән очракта компенсация билгеләү тәртибе (алга таба – 918 номерлы тәртип).

1.5. Бу регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк (күпфункцияле үзәк) – дәүләт учреждениесенең яки муниципаль учреждениенең оешу-хокук формасында төзелгән (шул исәптән автономияле учреждение булып торучы), 210-ФЗ номерлы федераль законда билгеләнгән таләпләргә җавап бирә торган һәм, шул исәптән электрон формада, «бер тәрәзә» принцибы буенча дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыруга вәкаләтле оешма;

дәүләт хезмәтләрен һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыны – дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль

хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасының шәһәр яки муниципаль район (шәһәр округы) авыл җирлегендә булдырылган территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы);

техник хата – дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка (дәүләт хезмәте нәтиҗәсендә) кертелгән белешмәләрнең, белешмәләр шуларга нигезләнеп кертелүче документлардагы белешмәләрнең ярашсызлыгына китергән хата (язу, басма хата, грамматик яки арифметик хата).

Бу Регламентта дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гариза дигәндә (алга таба – гариза) дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгать (210-ФЗ номерлы федераль законның 2 статьясының 1 пункты).

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләпнең атамасы | Стандартка карата таләпләр эчтәлеге | Хезмәтне яки таләпне билгели торган норматив хокукый акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәтенең аталышы | Торак урыннан һәм (яки) торак йорттан файдаланганда коммуналь хезмәтләрне кулланучы гражданнар тарафыннан коммуналь хезмәтләр өчен кертелә торган түләү күләмен фактик арттыру Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә коммуналь хезмәтләр өчен гражданнар тарафыннан кертелә торган түләү күләмен үзгәртүнең билгеләнгән чик дәрәҗә (максималь) индексларын арттырып җибәргән очракта компенсация (алга таба – компенсация) билгеләү. | 918 номерлы тәртипнең 1.1 пункты |
| 2.2. Дәүләт хезмәтен турыдан-туры күрсәтүче башкарма хакимият органы (учреждение) исеме | Татарстан Республикасы муниципаль районында яисә шәһәр округында «Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» дәүләт казна учреждениесе бүлеге | 918 номерлы тәртипнең 1.2 пункты |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенә тасвирлама | Компенсация билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар | 918 номерлы тәртипнең 1.2 пункты |
| 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү чоры, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә | Компенсация бирү (бирүдән баш тарту) турында карар шушы Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән гариза һәм документлар теркәлгән көннән башлап ун эш көне эчендә кабул ителә. | 918 номерлы тәртипнең 2.10 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| алып, Россия Федерациясе законнарында туктатып тору мөмкинлеге каралган очракта дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору чоры, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булып торган документларны бирү (җибәрү) срогы | Россия Федерациясе законнарында дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору мөмкинлеге каралмаган.<br>Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул ителгән вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла. | |
| 2.5. Закон яки башка төрле норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен, шулай ук дәүләт хезмәтен һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булып торган хезмәтләрне күрсәтү өчен,<br>кирәкле һәм зарури булып торган, гариза бирүче тарафыннан тапшырылырга тиешле документларның тулы исемлеге, шул исәптән электрон формада, аларны тапшыру тәртибе | 1. Компенсацияне банкта яки башка кредит учреждениесендә алган очракта, банкта яки башка кредит учреждениесендә ачылган шәхси счет реквизитларын, компенсация алу ысулын күрсәтеп, компенсация бирү турында гариза. Гаризаның киңәш ителә торган рәвеше шушы Регламентка карата 1 нче кушымтада китерелде.<br>2. Законлы вәкилләрнең яки ышанычнамә нигезендә Россия Федерациясе законнары нигезендә компенсация алу хокукына ия булган гражданнарның мәнфәгатьләрен белдерүгә вәкаләтле затларның вәкаләтләрен раслаучы документларның күчермәләре.<br>3. Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясеннән бирелгән, гариза бирүченең компенсациягә хокукын раслаучы билгеләнгән чик дәрәҗә индексның артуы турында мәгълүматны үз эченә алган документларның күчермәләре.<br>Күпфатирлы йортларда торак урыннарның милекчеләре өстәмә рәвештә аңа карата хокук Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында | 918 номерлы тәртипнең 2.8 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| | теркәлмәгән торак урынга хокук билгели торган документларның күчермәләрен дә тапшыра.<br>Документлар һәм белешмәләр гариза бирүче тарафыннан тиешле оешмаларда – турыдан-туры, шул исәптән, мондый мөмкинлек булган очракта, электрон рәвештә алына.<br>Гариза бирүченең законлы вәкилләре (законнарда каралган очракларда) яисә дәүләт хезмәтен алучылар тарафыннан вәкаләт бирелгән затлар, өстәмә рәвештә, гариза бирүченең мәнфәгатьләрен белдерүгә үзләренең вәкаләтләрен раслый торган документларның күчермәләрен дә тапшыра.<br>Документларның күчермәләре законнарда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, төп нөсхәләре белән бергә тапшырыла, алар төп нөсхәләрен күрсәтеп тапшырыла һәм Үзәк бүлеге хезмәткәре тарафыннан таныклана.<br>Гариза бирүче мөрәҗәгать иткәндә шәхесен таныклаучы документны күрсәтә.<br>Дәүләт хезмәте алу буенча гариза бланкын гариза бирүче Үзәк бүлегенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Гариза бланкының электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар гариза бирүче тарафыннан кәгазьдә яисә почта аша хат итеп тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин. Гаризаны почта аша җибәргәндә аңа теркәлә торган документларның күчермәләре (шәхесне таныклый | |

| | | |
|---|---|---|
| | торган документ күчермәсеннән кала) Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланган булырга тиеш.<br>Гариза һәм электрон документ формасындагы документлар Үзәк бүлегенә, «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып җибәрелергә мөмкин | |
| 2.6. Норматив хокукый актлар нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле булган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган һәм гариза бирүче тапшырырга хокуклы документларның тулы исемлеге, гариза бирүчеләр тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада да, аларны тапшыру тәртибе; әлеге документлар белән эш итүче дәүләт органы, җирле үзидарә органы яки оешма | Ведомствоара хезмәттәшлек итү каналлары аша түбәндәге мәгълүматларны үз эченә алган документлар алына:<br>дәүләт хезмәтен алучы белән бергә даими яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар турында (вәкаләтле органнарда);<br>аңа карата хокук Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында теркәлгән торак урынга милекчелек хокукы турында (Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография буенча федераль хезмәттә (алга таба – Росреестр);<br>дәүләтнең яки муниципаль торак фондындагы торак урыннан файдалануның хокукый нигезләре турында (вәкаләтле органнарда);<br>торак урынның мәйданы, кулланыла торган коммуналь хезмәтләрнең күләме, гариза бирүченең коммуналь хезмәтләр өчен түләү күләме тиешле муниципаль берәмлек өчен билгеләнгән чик дәрәҗә индексы күләменнән фактик артып киткән чор өчен коммуналь хезмәтләргә түләү күләмнәре һәм база | 918 номерлы тәртипнең 2.9 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| | аенда (алдагы календарь елының декабрендә, әгәр Россия Федерациясе законнарында башкача билгеләнмәсә) кулланылган коммуналь хезмәтләр өчен түләү күләмнәре турында (вәкаләтле органнарда).<br>Гариза бирүче яисә билгеләнгән тәртиптә таныкланган ышаныч кәгазе нигезендә гариза бирүче мәнфәгатьләрендә эш итүче зат әлеге пунктта күрсәтелгән белешмәләрне үз эченә алган документларны, шул исәптән мөмкинлек булганда электрон формада да, тапшырырга хокуклы.<br>Югарыда күрсәтелгән белешмәләрдән торучы документларның гариза бирүче тарафыннан тапшырылмавы гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.<br>Гариза бирүче тапшрырырга хокуклы булган документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе шушы Регламентның 2.5 пунктында билгеләнде.<br>Үзәк бүлеге гариза бирүчедән түбәндәгеләрне таләп итәргә хокуклы түгел:<br>дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда аларны тапшыру яки гамәлгә ашыру күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;<br>210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, шул исәптән гариза бирүче тарафыннан дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен түләү кертелүен раслый | |

| | | |
|---|---|---|
| | торган, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнар, бүтән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалар карамагында булган документларны тапшыруны;<br>дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны беренче мәртәбә кабул итүдән баш тартканда яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, дәүләт хезмәтен күрсәткәндә булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны тапшыруны | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән баш тарту нигезләренең тулы исемлеге | 1. Документларда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган бетерелгән, өстәп язылган урыннар, сызылган сүзләр һәм төзәтмәләр булу.<br>2. Гариза бирүченең яшәү урыны буенча Үзәк бүлегенә мөрәҗәгать итүе | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләренең | Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен | |

| | | |
|---|---|---|
| тулы исемлеге | нигезләр каралмаган.<br>Компенсация билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итү нигезләре:<br>шушы Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелмәгән затның мөрәҗәгать итүе;<br>әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларның тапшырылмавы яки тулы булмаган күләмдә тапшырылуы;<br>төгәл булмаган белешмәләрнең тапшырылуы;<br>гариза бирүченең компенсация бирү артыннан мөрәҗәгать итү көненә коммуналь хезмәтләргә түләү буенча әҗәте булу яки гариза бирүче тарафыннан аны түләү буенча килешү шартларының үтәлмәве. | 918 номерлы тәртипнең 2.11 пункты |
| 2.9. Дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки бүтән төрле түләүне алу тәртибе, аның күләме һәм алыну нигезләре | Дәүләт хезмәте түләүсез нигездә күрсәтелә | |
| 2.10. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булган хезмәтләрнең исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы оешмалардан бирелә торган документ (документлар) турында белешмәләр | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм зарури булып саналучы хезмәтләрне күрсәтү өчен түләү алу тәртибе, аның күләме һәм алу | Зарури һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |

| | | |
|---|---|---|
| нигезләре | | |
| 2.12. Дәүләт хезмәтен, дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында гариза тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь чоры | Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тапшырганда һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты – 15 минуттан артык түгел.<br>Дәүләт хезмәте алучы аерым категорияләр өчен чират билгеләнмәгән. | Россия Федерациясе Президентының 601 номерлы указының 1 пункты |
| 2.13. Дәүләт хезмәтен һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган оешма тарафыннан күрсәтелә хезмәтне күрсәтү турында гариза бирүченең гаризасын теркәү срогы һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада | Кирәкле барлык документлары белән гариза килгән көнне.<br>Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән рәсми мөрәҗәгать ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә. | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза тутыру урыннарына, һәр дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле булган документларны тутыру үрнәкләре һәм аларның исемлекләре булган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат урнаштыру һәм рәсмиләштерү тәртибенә, шул | Дәүләт хезмәтен күрсәтү янгына каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән тәэмин ителгән биналарда гамәлгә ашырыла.<br>Инвалидлар өчен хезмәт күрсәтелә торган урынга каршылыксыз үтеп керү, шул исәптән объектларга каршылыкларсыз үтеп керү һәм чыгу мөмкинлеге, шулай ук, хезмәт күрсәтелә торган урынга үтеп керү максатларында, объект буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге тәэмин ителә.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында визуаль, текстлы | |

| | | |
|---|---|---|
| исәптән инвалидларны социаль яклау турында федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен файдалана алырлык булуын тәэмин итүгә карата таләпләр | һәм мультимедияле мәгълүмат гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла. | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтеннән һәркем файдалана алу мөмкинлеге һәм аның сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешкә кереп эшләү саны һәм аларның вакыты буенча озынлыгы, дәүләт хезмәтен күрсәтү барышында, шул исәптән мәгълүмат-телекоммуникация технологияләреннән файдаланып, мәгълүматны алу мөмкинлеге, дәүләт хезмәтен дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган күпфункцияле үзәктә, гариза бирүче ихтыярына карап (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган күпфункцияле үзәктә берничә дәүләт хезмәтен алу турында 210-ФЗ номерлы федераль законның 15[1] статьясында каралган гаризаны (комплекслы мөрәҗәгатьне) тапшыру | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең үтемле булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>инвалидларга аларга бүтән затлар белән бертигез дәрәҗәдә хезмәтләр алуга комачау итүче киртәләрне җиңүдә ярдәм күрсәтү;<br>инвалидларга биналарның инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итүгә бәйле булмаган, аларга башка затлар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләр алуга комачаулый торган бүтән каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтү;<br>дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарның инвалидлар өчен үтемле булуы;<br>Үзәк бүлекләре бүлмәләренең җәмәгать транспортыннан файдалану зонасында урнашкан булуы;<br>кирәкле санда белгечләр, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул итү гамәлгә ашырыла торган урыннар булуы;<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү ысуллары, тәртибе, вакытлары турында мәгълүмат стендларында, Интернет челтәрендә, Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль | 880 номерлы Тәртипнең 2.4 п.,<br>Россия Федерациясе Президентының 601 номерлы указының 1 пункты |

| | | |
|---|---|---|
| юлы белән дә, башкарма хакимият органының теләсә кайсы территориаль органында дәүләт хезмәтеннән файдалану мөмкинлеге (шул исәптән тулы күләмдә) яки файдалана алмау | яклау министрлыгының рәсми сайтында тулы мәгълүмат булу;<br>электрон рәвештә гариза тапшыру мөмкинлеге;<br>гариза бирүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләрен электрон формада Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша алу мөмкинлеге.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>документларны кабул итү һәм карау чорлары саклану;<br>дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу чоры саклану;<br>Үзәк бүлеге белгечләре тарафыннан Регламентны бозып кылынган прецедентларның (нигезле шикаятьләрнең) булмавы;<br>Гариза бирүченең Үзәк бүлеге белгечләре белән бергәләп эшләргә туры килгән очраклар саны:<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен зарури документларны турыдан-туры тапшырганда – бер мәртәбәдән артык түгел (консультацияләрне исәпкә алмыйча);<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны почта, шул исәптән электрон почта аша җибәргәндә турыдан-туры хезмәттәшлек итү таләп ителми.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гариза бирүченең Үзәк бүлеге белгече белән бер мәртәбә бәйләнешкә керүенең вакыт озынлыгы 15 минуттан артмый.<br>Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган | |

| | | |
|---|---|---|
| | күпфункцияле үзәк аша, күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыннары аша дәүләт хезмәте күрсәтү буенча гариза тапшыруны да кертеп, дәүләт хезмәте дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге аша күрсәтелми.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүмат гариза бирүче тарафыннан http://mtsz.tatarstan.ru сайтыннан, Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең бердәм порталыннан, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatarstan.ru/) алынырга мөмкин.<br>Экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы мөрәҗәгать составында дәүләт хезмәте күрсәтелми | |
| 2.16. Башка, шул исәптән экстерриториаль принцип буенча дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган таләпләр | Гариза һәм электрон документ формасындагы документлар Үзәк бүлегенә, «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып җибәрелергә, шулай ук электрон саклагычлардан файдаланып, гариза бирүче тарафыннан Үзәк бүлегенә тапшырылырга мөмкин. Шул ук вакытта гариза гади электрон имза белән имзаланган булырга тиеш, ә гаризага теркәлә торган документларның күчермәләре 63-ФЗ номерлы федераль закондагы һәм 210-ФЗ номерлы федераль законның $21^1$ статьясы һәм $21^2$ статьясы таләпләре нигезендә законнарда билгеләнгән тәртиптә электрон имза белән таныкланган булырга тиеш. | 918 номерлы тәртипнең 2.8 пункты |

### 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада үтәү үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә гамәлләрнең эзлеклелегенә тасвирлама

3.1.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү, шул исәптән электрон рәвештә, түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) гариза бирүчене консультацияләү, аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә;

2) гаризаны һәм документларны кабул итү һәм теркәү;

3) мәгълүматлар алу, ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү;

4) компенсация билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар әзерләү;

5) гариза бирүчегә гражданин шәхси мөрәҗәгь иткәндә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

3.2. Мөрәҗәгать итүчене консультацияләү, аңа ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә

3.2.1. Гариза бирүче шәхсән, телефон, почта аша, электрон почта һәм (яисә) хат аша Үзәк бүлегенә дәүләт хезмәтеннән файдалану тәртибе турында консультацияләр алу өчен мөрәҗәгать итә.

Үзәк бүлеге белгече шәхсән, телефон аша, почта, электрон почта ярдәмендә, гариза бирүченең мөрәҗәгать итү ысулына карап, гариза бирүчене консультацияли, шул исәптән дәүләт хезмәте алу өчен кирәкле документларның составы, рәвеше һәм эчтәлеге буенча, гариза бланкы бирә һәм, зарурлык булганда, гариза бирүчегә ярдәм күрсәтә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: консультацияләү, тапшырылган документларның составы, рәвеше һәм эчтәлеге буенча кисәтүләр, гариза бирүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны рәсмиләштерү өлешендә.

3.3. Гаризаны һәм документларны кабул итү һәм теркәү

3.3.1. Гариза бирүче компенсация билгеләү турында гаризаны Үзәк бүлегенә, әлеге Регламентның 2.5 пунктына туры китереп, документларны теркәп тапшыра.

63-ФЗ номерлы федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә электрон имза белән имзаланган (таныкланган) электрон документ рәвешендәге гариза һәм документларның күчермәләре мөрәҗәгать итүче тарафыннан Үзәк бүлегенә электрон саклагыч җайланмаларыннан файдаланып һәм (яисә), «Интернет» челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре ярдәмендә тапшырылырга мөмкин.

Үзәк бүлегенә почта аша, шул исәптән электрон почта буенча, җибәрелгән гариза гомуми тәртиптә карала.

Үзәк бүлеге хезмәткәре дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле булган, шушы

Регламентның 2.7 пунктында каралган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булу-булмавын тикшерә.

Документларны кабул итүдән баш тарту нигезләре булмаганда, Үзәк бүлеге белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

гаризаны кабул итә һәм мөрәҗәгатьләрне теркәү журналында (2 нче кушымта) терки;

гаризаны һәм документларны кабул итү датасы, беркетелгән керү номеры турында тамгалап (гариза бирүче шәхсән мөрәҗәгать иткәндә), гаризаны гариза бирүчегә язу тапшыру, почта аша, шул исәптән электрон почта аша, хәбәрләмә җибәрү (документлар почта, шул исәптән электрон почта, аша җибәрелгән очракта).

Документларны кабул итүдән һәм гаризаны теркәүдән баш тарту нигезләре булган очракта, Үзәк бүлеге белгече гариза бирүчегә документларны кайтарып бирә һәм гариза бирүчегә, документларны кабул итүдән һәм гаризаны теркәүдән баш тартуда ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген язмача аңлатып, документларны кабул итүдән баш тарту турында хәбәр итә.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедуралар түбәндәгечә башкарыла:

шәхсән кабул иткәндә, – гариза һәм документлар килгән көнне;

гариза һәм документлар почта аша, шул исәптән электрон почта аша электрон документлар рәвешендә килгәндә, – гариза һәм документлар Үзәк бүлегенә килгән көнне яисә, гариза һәм документлар Үзәк бүлегенең эш вакыты тәмамлангач килгән очракта, киләсе көнне. Гариза һәм документлар (документларның күчермәләре) почта аша, шул исәптән электрон документлар рәвешендә электрон почта ярдәмендә ял көннәрендә яисә эшләми торган бәйрәм көннәрендә килгән очракта, – Үзәк бүлегенең ял көненнән яисә эшләми торган бәйрәм көненнән соңгы беренче эш көнендә.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән гариза һәм документлар, гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында теркәлгән язу, документларны кабул итүдән баш тарту турында язу яисә гариза бирүчегә баш тарту турында хәбәр итү, гариза бирүчегә кайтарылган документлар.

3.4. Мәгълүматлар алу, ведомствоара рәсми мөрәҗәгатьләр формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга җибәрү

3.4.1. Үзәк бүлеге белгече электрон рәвештә түбәндәге белешмәләрне ала:

вәкаләтле оешмалардан законнар нигезендә компенсациягә хокукы булган гражданин белән бергә даими яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар турында белешмәләр;

Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында теркәлгән торак урынга милекчелек хокукы турында белешмәләр;

дәүләт яки муниципаль торак фондындагы торак урыныннан файдалануның хокукый нигезләре турында вәкаләтле оешмалардан белешмәләр;

торак урынның мәйданы, кулланыла торган коммуналь хезмәтләрнең күләме, гариза бирүченең коммуналь хезмәтләр өчен түләү күләме тиешле муниципаль берәмлек өчен билгеләнгән чик дәрәҗә индексы күләменнән фактик артып киткән чор өчен коммуналь хезмәтләргә түләү күләмнәре һәм база аенда (алдагы календарь елының декабрендә, әгәр Россия Федерациясе законнарында башкача билгеләнмәсә)

кулланылган коммуналь хезмәтләр өчен түләү күләмнәре турында вәкаләтле оешмалардан белешмәләр.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны һәм документларны кабул иткән һәм теркәгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: электрон формада алынган һәм «Татарстан Республикасы халкының социаль регистры» дәүләт мәгълүмат системасына (алга таба – Система), Системаның «Социаль ярдәм чаралары» өлешенә кертелгән белешмәләр.

3.4.2. Компенсация билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар кабул итү өчен кирәкле белешмәләр Үзәк бүлегендә булмаганда, Үзәк бүлеге белгече электрон рәвештә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасы ярдәмендә түбәндәге белешмәләрне сората:

вәкаләтле оешмалардан законнар нигезендә компенсациягә хокукы булган гражданин белән бергә даими яшәү урыны буенча теркәлгән гражданнар турында белешмәләр;

Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында теркәлгән торак урынга милекчелек хокукы турында белешмәләр;

дәүләт яки муниципаль торак фондындагы торак урыныннан файдалануның хокукый нигезләре турында вәкаләтле оешмалардан белешмәләр;

торак урынның мәйданы, кулланыла торган коммуналь хезмәтләрнең күләме, гариза бирүченең коммуналь хезмәтләр өчен түләү күләме тиешле муниципаль берәмлек өчен билгеләнгән чик дәрәҗә индексы күләменнән фактик артып киткән чор өчен коммуналь хезмәтләргә түләү күләмнәре һәм база аенда (алдагы календарь елының декабрендә, әгәр Россия Федерациясе законнарында башкача билгеләнмәсә) кулланылган коммуналь хезмәтләр өчен түләү күләмнәре турында вәкаләтле оешмалардан белешмәләр.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гаризаны һәм документларны кабул иткән һәм теркәгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: белешмәләр бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр.

3.5. Компенсация билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар әзерләү.

3.5.1. Үзәк бүлеге белгече алынган, әлеге Регламентның 3.4.1 пунктында күрсәтелгән белешмәләр һәм әлеге Регламентның 3.4.2 пунктында күрсәтелгән, ведомствоара хезмәттәшлек итү органнарыннан законнарда билгеләнгән срокларда килгән белешмәләр нигезендә һәм гариза бирүче тапшырган документлар нигезендә түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

дәүләт хезмәтеннән файдаланучы затның законлы вәкиле яисә аның тарафыннан вәкаләт бирелгән зат мөрәҗәгать иткән очракта, гариза бирүченең вәкаләтләрен тикшерә;

компенсация билгеләүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.8 пунктында каралган нигезләр булу-булмавын тикшерә;

әлеге Регламентның 3 нче кушымтасына туры китерелгән рәвештә компенсация билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) электрон рәвештә карар проекты рәсмиләштерә;

компенсация билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) электрон

рәвештәге карар проектын имза салу өчен Үзәк бүлеге җитәкчесенә юллый.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар рәсми мөрәҗәгатьләргә җавап килгән көннән соң ике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла, ләкин гаризаны теркәгән көннән соң җиде эш көнненән дә соңга калмыйча.

Процедураларның нәтиҗәсе: компенсация билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар проекты.

3.5.2. Үзәк бүлеге җитәкчесе документларны караганнан соң компенсация билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) электрон рәвештәге карарга электрон цифрлы имза куя һәм Үзәк бүлеге белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура документларны компенсация билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар проекты җибәрелгән көннән башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Үзәк бүлеге җитәкчесе имзалаган компенсация билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар.

3.6. Гариза бирүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирү

Үзәк бүлеге белгече гариза бирүче күрсәткән ысул белән (почта адресы буенча язмача формада, электрон почта адресы буенча электрон документ формасында, телефонга смс-хәбәр итеп) гариза бирүчегә компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында кабул ителгән карар турында хәбәр итә.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамланган көннән башлап бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында кабул ителгән карар буенча хәбәрләмә.

3.7. Техник хаталарны төзәтү

Техник хатаны төзәтү гариза бирүче тарафыннан, гариза бирүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе буларак бирелгән, техник хатасы булган документны (андый документ бирелгән булса) теркәп, әлеге Регламентның 4 нче кушымтасына ярашлы форма буенча гариза бирелгәндә гамәлгә ашырыла.

3.7.1. Үзәк бүлеге белгече:

техник хата төзәтү турында гаризаны кабул итә һәм гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү журналында терки (әлеге Регламентның 2 нче кушымтасы);

компенсация билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) электрон рәвештәге карар проектын үзгәртеп рәсмиләштерә;

компенсация билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) яңадан рәсмиләштерелгән карар проектын электрон формада имза салу өчен Үзәк бүлеге җитәкчесенә юллый.

Шушы пунктта билгеләнә торган процедура гариза кергән көндә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: техник хата төзәтү турында кабул ителгән һәм теркәлгән гариза, Үзәк бүлеге җитәкчесенә имза салу өчен юлланган компенсация билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) үзгәртеп рәсмиләштерелгән электрон рәвешле карар проекты.

3.7.2. Үзәк бүлеге җитәкчесе компенсация билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) үзгәртеп рәсмиләштерелгән карарга электрон цифрлы имза куя һәм аны Үзәк бүлеге белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура карар проекты имза салу өчен

җибәрелгән вакыттан башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Үзәк бүлеге җитәкчесе имзалаган компенсация билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар.

3.7.3. Үзәк бүлеге белгече гариза бирүчегә гаризада күрсәтелгән ысул белән (почта адресы буенча, электрон почта адресы аша, телефонга смс-хәбәр рәвешендә), компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту турында) яңадан рәсмиләштерелгән карар турында хәбәр итә.

Әлеге пунктчада билгеләнә торган процедура аннан алдагы процедура тәмамланган көннән башлап бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: компенсация билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар турында гариза бирүчегә хәбәр итү.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору тәртибе һәм рәвешләре

4.1. Үзәк бүлегендәге хезмәткәрләрнең Регламентның һәм дәүләт хезмәте күрсәтү буенча таләпләр билгели торган бүтән норматив хокукый актларның нигезләмәләрен үтәвен һәм башкаруын көндәлек тикшереп тору Үзәк бүлеге җитәкчесе тарафыннан әлеге Регламент нигезләмәләрен үтәүгә һәм башкаруга карата тикшерүләр уздыру юлы белән гамәлгә ашырыла. Үзәк бүлеге җитәкчесе тарафыннан карарлар кабул ителүне көндәлек тикшереп торуны оештыру тәртибен һәм рәвешләрен Үзәк директоры билгели.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшереп тору Министрлык аппараты бүлегенең һәм Министрлыкның Татарстан Республикасы муниципаль районында яисә шәһәр округында Социаль яклау идарәсенең (бүлегенең) әлеге тикшереп торуны гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазыйфаи затлары тарафыннан гамәлгә ашырыла, аларның вәкаләтләре Министрлыкның структур бүлекчәсе турында нигезләмәдә һәм хезмәткәрләрнең вазыйфаи регламентларында билгеләнә.

Административ процедуралар үтәлешен тикшереп тору рәвешләре түбәндәгеләргә карата тикшерүләр уздырудан гыйбарәт:

эшнең алып барылуына;

белешмәләрне һәм документларны карау нәтиҗәләренең законнардагы (шушы Регламенттагы) таләпләргә туры килүенә;

гаризаларны һәм документларны кабул итүнең чорлары һәм тәртибе саклануга;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә нәтиҗәләр тапшыру чорлары һәм тәртибе саклануга.

Тикшерүләрне үткәрү ешлыгы планлы характерга (эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш характерга (гариза бирүченең конкрет мөрәҗәгате буенча) ия.

4.3. Уздырылган тикшерүләр нәтиҗәсендә гариза бирүчеләрнең хокуклары бозылу очраклары ачыкланган очракта, Үзәк хезмәткәрләре, Министрлыкның вазыйфаи затлары дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә кабул ителә (гамәлгә ашырыла) торган карарлар һәм гамәлләр (гамәл кылмаган) өчен Россия Федерациясе

законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.

4.4. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә Үзәк бүлеге эшчәнлегенең ачык булуы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм төгәл мәгълүматны алу мөмкинлеге һәм дәүләт хезмәте күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр тәртиптә карау юлы белән гамәлгә ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтә торган орган, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтә торган күпфункцияле үзәк карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Гариза бирүчеләр судка кадәр тәртиптә Үзәк бүлегенең дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган хезмәткәрләре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата Үзәк бүлеге җитәкчесенә дәгъва белдерү хокукына ия.

Үзәк бүлеге җитәкчесе карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр Үзәк җитәкчесенә тапшырыла.

Үзәк җитәкчесе карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр Министрлыкка тапшырыла.

Министр карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына шикаять белдерелергә мөмкин.

5.2. Гариза бирүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

дәүләт хезмәте күрсәтү турында рәсми мөрәҗәгатьне теркәү срогы бозылганда;

дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты бозылганда;

гариза бирүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен тапшырылуы яки гамәлгә ашырылуы күздә тотылмаган документларны яки мәгълүматларны яисә гамәлләр башкаруны таләп иткәндә;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны гариза бирүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм бүтән норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса;

дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп ителгәндә;

дәүләт хезмәте күрсәтүче орган (учреждение), дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи зат (учреждение белгече) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда үзләре тарафыннан җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тарткан очракта яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән чоры бозылганда;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү чоры яисә

тәртибе бозылганда;

дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм норматив хокукый актларында туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралганнардан тыш, булмавы һәм (яки) дөрес булмавы турында күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны гариза бирүчедән таләп иткәндә.

5.3. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның (учреждениенең), дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның (учреждение белгеченең), дәүләт хезмәте күрсәтүче дәүләт хезмәткәренең, орган (учреждение) җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять язмача формада кәгазьдә яисә электрон формада тапшырыла.

Дәүләт хезмәте алучылар тарафыннан шикаять почтадан, күпфункцияле үзәктән, «Интернет» челтәреннән файдаланып, Министрлыкның рәсми сайтыннан (http://www.mtsz.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatarstan.ru/), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (https://www.gosuslugi.ru/) җибәрелергә, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул иткәндә кабул итеп алынырга мөмкин.

5.4. Шикаятьләрне карау чоры – аны теркәүгә алганнан соң унбиш эш көне эчендә һәм дәүләт хезмәте күрсәтә торган органның (учреждениенең) гариза бирүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта, – аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.

5.5. Шикаятьтә түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (учреждениенең), дәүләт хезмәте күрсәтүче органда вазыйфаи затның (учреждение белгеченең) яисә граждан хезмәткәренең исеме;

2) гариза бирүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), яшәгән урыны турында белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта ) һәм гариза бирүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (учреждениенең), дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның (учреждение белгеченең) яисә дәүләт хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүматлар;

4) гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның (учреждениенең), дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның (учреждение белгеченең) яисә дәүләт хезмәткәренең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән

ризалашмавын нигезләүче дәлилләр.

Гариза бирүче тарафыннан аның дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.6. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган (учреждение) тарафыннан җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, гариза бирүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алынуы каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Әлеге пунктның 1 һәм 2 пунктчаларында күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән соңгы көннән соңга калмыйча гариза бирүчегә язмача яки, аның ихтыярына карап, электрон рәвештә шикаятьне карау нәтиҗәләре турында нигезле җавап җибәрелә.

5.7. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, җавапта гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән юк итү максатларында дәүләт хезмәте күрсәтүче орган (учреждение) тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәтеннән файдалану максатларында алга таба гариза бирүче эшләргә тиешле гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерергә тиешле түгел дип танылган очракта, гариза бирүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.9. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карау вәкаләте бирелгән вазыйфаи зат, учреждение белгече булган материалларны прокуратура органнарына кичекмәстән җибәрә.

5.10. Үзәк бүлекләренең, шулай ук аның вазыйфаи затлары карарларына һәм гамәлләренә судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләр 210-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә җайга салына.

Торак урыннан һәм (яки) торак йорттан файдаланганда коммуналь хезмәтләрне кулланучы гражданнар тарафыннан коммуналь хезмәтләр өчен кертелә торган түләү күләмен фактик арттыру Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә коммуналь хезмәтләр өчен гражданнар тарафыннан кертелә торган түләү күләмен үзгәртүнең билгеләнгән чик дәрәҗә (максималь) индексларын арттырып җибәргән очракта компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

Киңәш ителә торган рәвеше

Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге ДКУ №___ бүлегенә
______________________________________________
муниципаль районында (шәһәр округында)

ГАРИЗА № ____
20____ елның «_____» ________

Мин, ____________________________________________________________________________,
(гариза бирүченең, ышанычлы затның яки законлы вәкилнең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта))
түбәндәге адрес буенча яшим:
_________________________________________________________________________________,
(гариза бирүченең почта адресы, индексы, телефоны, электрон почта адресы)

| Шәхес таныклаучы документ атамасы | Сериясе һәм (яки) номеры | Кем тарафыннан бирелгән | Бирелгән датасы |
|---|---|---|---|
| | | | |

Эш итү нигезе: _______________________________________________________
(гариза бирүченең дәүләт хезмәтенән файдаланучы зат мәнфәгатьләрендә эш итүен раслый торган документларның реквизитлары, ышанычлы зат яисә законлы вәкил мөрәҗәгать иткән очракта)

Торак урыннан һәм (яки) торак йорттан файдаланганда коммуналь хезмәтләрне кулланучы гражданнар тарафыннан коммуналь хезмәтләр өчен кертелә

торган түләү күләмен фактик арттыру Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә коммуналь хезмәтләр өчен гражданнар тарафыннан кертелә торган түләү күләмен үзгәртүнең билгеләнгән чик дәрәҗә (максималь) индексларын арттырып җибәргән очракта компенсация билгеләү турында үтенәм.

______________________________________________________________________________
(гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта))
СНИЛС (гариза бирүченеке) ______________
Түбәндәге документларны (белешмәләрне) тапшырам:

| | Документларның аталышы | Нөсхәләр саны |
|---|---|---|
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |
| | | |

Билгеләнгән түләүләрне түбәндәгечә түләүне сорыйм:
счетка күчерү юлы белән

______________________________________________________________________________
(гариза бирүченең, ышанычлы затның яки законлы вәкилнең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта))
почта бүлеге аша

___________________________________________________________________________
(гариза бирүченең почта бүлеге, ышанычлы зат яки законлы вәкил реквизитлары күрсәтелә)

Тапшырылган белешмәләрнең дөреслеге, аларны үз эченә алган документларның төп нөсхәләре өчен җаваплылык турында һәм социаль ярдәм чаралары түләүгә йогынты ясый торган шартларның үзгәрүе турында вакытында хәбәр итү бурычы турындагы нигезләмәләр белән таныштым

Гариза бирүче: ____________________________ ________ «__» __________20__ ел.
(гариза бирүченең, ышанычлы затның яки законлы вәкилнең фамилиясе, исеме, атасының исеме, имзасы)

Мәгълүматлар алуга, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында, риза___________________________________________________________
(почта адресы буенча хат белән, смс-хәбәр итеп, электр почта адресы буенча электрон почта белән)

«__» __________20__ ел. Имза ___________

Гариза һәм документлар кабул ителде ______ 20__ ел.

_________ ______________________________
(белгечнең имзасы, тулы имзасы)

___________________________________________________________________________

Өзү линиясе
Язу-белдерү
Гариза бирүченең теркәлү номеры
Документлар саны ____ данә, __ биттә
Документларны кабул итте ____________ __________ ______________ ______ 20__ ел.
(вазыйфа) (имза) (тулы имза) (дата)

Торак урыннан һәм (яки) торак йорттан файдаланганда коммуналь хезмәтләрне кулланучы гражданнар тарафыннан коммуналь хезмәтләр өчен кертелә торган түләү күләмен фактик арттыру Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә коммуналь хезмәтләр өчен гражданнар тарафыннан кертелә торган түләү күләмен үзгәртүнең билгеләнгән чик дәрәҗә (максималь) индексларын арттырып җибәргән очракта компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта

Гражданнарның мөрәҗәгатьләрен теркәү
ЖУРНАЛЫ

| № п/п | Мөрәҗәгать итү датасы | Мөрәҗәгать номеры | Гражданинның ФИА | Адресы | Мөрәҗәгать итү сәбәпләре | Мөрәҗәгать нәтиҗәләре | Сәбәпләре күрсәтелмәгән мөрәҗәгать нәтиҗәләре |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | |

Торак урыннан һәм (яки) торак йорттан файдаланганда коммуналь хезмәтләрне кулланучы гражданнар тарафыннан коммуналь хезмәтләр өчен кертелә торган түләү күләмен фактик арттыру Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә коммуналь хезмәтләр өчен гражданнар тарафыннан кертелә торган түләү күләмен үзгәртүнең билгеләнгән чик дәрәҗә (максималь) индексларын арттырып җибәргән очракта компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта

Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге ДКУ №___ бүлегенә ___________________________________ муниципаль районында (шәһәр округында)

Социаль ярдәм чаралары билгеләү (бирү) турында
карар

№ _________ «__» _________

Гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме
_____________________________________________________________________
Гариза бирүченең адресы_______________________________________________

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 17 октябрендәге 918 номерлы карары нигезендә торак урыннан һәм (яки) торак йорттан файдаланганда коммуналь хезмәтләрне кулланучы гражданнар тарафыннан коммуналь хезмәтләр өчен кертелә торган түләү күләмен фактик арттыру Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә коммуналь хезмәтләр өчен гражданнар тарафыннан кертелә торган түләү күләмен үзгәртүнең билгеләнгән чик дәрәҗә (максималь) индексларын арттырып җибәргән очракта компенсация билгеләргә (бирергә)

| № | Социаль ярдәм чаралары | Билгеләү датасы | Түләү срогы ____ башлап _____ кадәр |
|---|---|---|---|
| 1 | компенсация | | ___башлап____ |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | кадәр |

Түләү ысулы

________________________________________________________________

Бүлек җитәкчесе _______________ _________________
(Ф.И.А.) имза

мөһер урыны

Бүлек белгече ________________ _________________
(Ф.И.А.) имза

Гариза бирүчегә хәбәр ителде:

Почта адресы буенча язмача ________________________________________

смс-хәбәр белән ______________________
(телефон номеры)

электрон почта аша ____________________________________
(электрон почта адресы)

«Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ № ___ бүлегенә

_______________________________
муниципаль районында
(шәһәр округында)

Социаль ярдәм чаралары билгеләүдән (бирүдән) баш тарту турында
карар

№ _____ «__» ___________

Гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме

_____________________________________________________________________

Гариза бирүченең адресы ___________________________________________________

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 17 октябрендәге 918 номерлы карары нигезендә торак урыннан һәм (яки) торак йорттан файдаланганда коммуналь хезмәтләрне кулланучы гражданнар тарафыннан коммуналь хезмәтләр өчен кертелә торган түләү күләмен фактик арттыру Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә коммуналь хезмәтләр өчен гражданнар тарафыннан кертелә торган түләү күләмен үзгәртүнең билгеләнгән чик дәрәҗә (максималь) индексларын арттырып җибәргән очракта компенсация билгеләүдән (бирүдән) баш тартырга.

Баш тарту сәбәбе:_____________________________________________________

Бүлек җитәкчесе _______________ _________________
(Ф.И.А.) имза

мөһер урыны

Бүлек белгече _________________ __________________
(Ф.И.А.) имза
Гариза бирүчегә хәбәр ителде:
Почта адресы буенча язмача____________________________________________

sms-хәбәр белән ___________________________
(телефон номеры)
электрон почта аша _______________________________________
(электрон почта адресы)

Торак урыннан һәм (яки) торак йорттан файдаланганда коммуналь хезмәтләрне кулланучы гражданнар тарафыннан коммуналь хезмәтләр өчен кертелә торган түләү күләмен фактик арттыру Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә коммуналь хезмәтләр өчен гражданнар тарафыннан кертелә торган түләү күләмен үзгәртүнең билгеләнгән чик дәрәҗә (максималь) индексларын арттырып җибәргән очракта компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 4 нче кушымта

Киңәш ителә торган рәвеше

«Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге» ДКУ № ___ бүлегенә
________________________________
муниципаль районында
(шәһәр округында)

Техник хата төзәтү турында
гариза

Мин,____________________________________________________________
(гариза бирүченең, ышанычлы затның яки законлы вәкилнең фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта))
яши торган адрес: ______________________________________________________
________________________________________________________________,
(гариза бирүченең почта адресы, индексын күрсәтеп, телефоны, электрон адресы)
________________________________________________________________
(гариза бирүченең, ышанычлы затның яки законлы вәкилнең шәхесен раслаучы документның исеме, сериясе, номеры, бирелгән датасы, документны биргән орган атамасы)
техник хатаны төзәтүне сорыйм________________________________________, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 17 октябрендәге 918 номерлы карары нигезендә торак урыннан һәм (яки) торак йорттан файдаланганда коммуналь хезмәтләрне кулланучы гражданнар тарафыннан коммуналь хезмәтләр өчен кертелә торган түләү күләмен фактик арттыру Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә коммуналь хезмәтләр өчен гражданнар тарафыннан кертелә торган түләү күләмен үзгәртүнең билгеләнгән чик дәрәҗә (максималь) индексларын арттырып җибәргән очракта компенсация билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында _______________ карарда җибәрелгән.
(карар реквизитлары, бирелү датасы)

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 17 октябрендәге 918 номерлы карары нигезендә торак урыннан һәм (яки) торак йорттан файдаланганда коммуналь хезмәтләрне кулланучы гражданнар тарафыннан коммуналь хезмәтләр өчен кертелә торган түләү күләмен фактик арттыру Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә коммуналь хезмәтләр өчен гражданнар тарафыннан кертелә торган түләү күләмен үзгәртүнең билгеләнгән чик дәрәҗә (максималь) индексларын арттырып җибәргән очракта компенсация билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар алуга риза ________________________________________
(почта адресына язмача формада, электрон почта адресына электрон документ формасында, телефонга смс-хәбәр итеп)
«__» ___________ 20__ ел.
_______________________ _____________________________
(гариза бирүченең имзасы) (тулы имза)

Торак урыннан һәм (яки) торак йорттан файдаланганда коммуналь хезмәтләрне кулланучы гражданнар тарафыннан коммуналь хезмәтләр өчен кертелә торган түләү күләмен фактик арттыру Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә коммуналь хезмәтләр өчен гражданнар тарафыннан кертелә торган түләү күләмен үзгәртүнең билгеләнгән чик дәрәҗә (максималь) индексларын арттырып җибәргән очракта компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (белешмәлек) кушымта

Торак урыннан һәм (яки) торак йорттан файдаланганда коммуналь хезмәтләрне кулланучы гражданнар тарафыннан коммуналь хезмәтләр өчен кертелә торган түләү күләмен фактик арттыру Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә коммуналь хезмәтләр өчен гражданнар тарафыннан кертелә торган түләү күләмен үзгәртүнең билгеләнгән чик дәрәҗә (максималь) индексларын арттырып җибәргән очракта компенсация билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшерүдә тоту өчен җаваплы булган органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр

«Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге»
дәүләт казна учреждениесе

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Директор | 523-90-40 | koord.rcmp@tatar.ru |

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр | 557-20-01 | mtsz@tatar.ru |
| Министр урынбасары | 557-20-08 | Natalya.Butaeva@tatar.ru |
| Социаль ярдәм чараларының методология бүлеге башлыгы | 557-20-77 | Elena.Zenina@tatar.ru |
| Социаль ярдәм чараларының аудит бүлеге башлыгы | 557-20-86 | Elvira.Pislegina@tatar.ru |